РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ЮЛБАТСКИЙ СЕЛЬСКИЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА

422077, Республика Татарстан,
с. Юлбат, ул. Г.Тукая, 57
тел. (84362) 43-7-22

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ЮЛБАТ АВЫЛ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422077, Татарстан Республикасы,
Юлбат авылы, Г.Тукай урамы, 57 йорт
тел. (84362) 43-7-22

e-mail: Ulbat.Sab@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
18.02.2022

КАРАР
№ 5

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында кулланыла торган тикшерү кәгазе формасын (контроль сораулар исемлеген) раслау турында

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында" 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 53 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат авыл башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында кулланыла торган тикшерү кәгазе формасын (контроль сораулар исемлеген) расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча, Саба муниципаль районының Юлбат авыл җирлегенең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/rus/ulbat адресы буенча бастырып чыгарырга һәм җирлекнең мәгълүмати стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә калдырам.

Юлбат авыл җирлеге башлыгы Т.Р. Шәмсиев

РАСЛАНГАН
Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районы Юлбат авыл
башкарма комитетының
2022 елның 18 февралендәге 5
номерлы карары белән

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында кулланыла торган тикшерү кәгазе формасы (контроль сораулар исемлеге)

Тикшерү кәгазенең (контроль сораулар исемлеге) әлеге формасы (алга таба - тикшерү кәгазе) Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында үткәрелә торган планлы тикшерүләр барышында кулланыла.

Планлы тикшерү предметы әлеге тикшерү кәгазенә кертелгән мәҗбүри таләпләрне үтәү белән чикләнә.

1. Муниципаль контроль органы исеме: ________________________________________
_______________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________.

2. Шәхси эшмәкәрнең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булса), ИНН, ОГРН/ОГРНИП, аңа карата тикшерү үткәрү: ________________________________________
_______________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________.

3. Тикшерү кәгазе тутырып планлы тикшерү үткәрү урыны:
_______________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________.

4. Тикшерү үткәрү турында күрсәтмә реквизитлары ______________________
_______________________________________________________________________________.

5. Тикшерүнең хисап номеры һәм тикшерүләрнең бердәм реестрында тикшерү хисап номерын бирү датасы _______________________________________________________.

6. Планлы тикшерү уздыручы һәм тикшерү кәгазе тутыручы вазыйфаи затның вазыйфасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме ________________________
_______________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________.

7. Юридик зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан тикшерү предметы булган мәҗбүри таләпләрнең үтәлүен яки үтәлмәвен раслый торган мәҗбүри таләпләрнең эчтәлеген чагылдыручы мәсьәләләр исемлеге:

| № п/п | Мәҗбүри таләпләрнең әчтәлеген чагылдыручы мәсьәләләр | Мәҗбүри таләпләр билгеләнгән структур берәмлекләрен күрсәтеп, норматив хокукый актлар реквизитлары | Сорауларга җаваплар | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Әйе | Юк | Килешмәү | Искәрмә |
| 1 | Милек хокукында, башка әйбер яки мәҗбүри хокукта, шулай ук гамәлдәге законнарда һәм җирлекне төзекләндерү Кагыйдәләрендә каралган күләмдә, мөстәкыйль рәвештә яки махсус оешмаларны үз акчалары хисабына җәлеп итү юлы белән биналар, корылмалар, җир кишәрлеге территориясен карап тоту һәм җыештыру эшләре алып барыламы? | Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеген төзекләндерү Кагыйдәләре (алга таба - авыл җирлеген төзекләндерү Кагыйдәләре) | | | | |
| 2 | Җир кишәрлеге яки бина янындагы территорияне карап тоту һәм җыештыру эшләре алып барыламы? | АҖ төзекләндерү Кагыйдәләре | | | | |
| 3 | Яшел үсентеләрне карап тоту тәртибе сакланамы? | АҖ төзекләндерү Кагыйдәләре | | | | |
| 4 | Үләннәр чабу тормышка ашырыламы? | АҖ төзекләндерү Кагыйдәләре | | | | |
| 5 | Якын-тирә территорияләрне төзекләндерү буенча эш алып барыламы? | АҖ төзекләндерү Кагыйдәләре | | | | |
| 6 | Бина һәм корылмаларны ремонтлау һәм буяу эшләре башкарыламы? | АҖ төзекләндерү Кагыйдәләре | | | | |
| 7 | Биналар янында чүп савытлары куелганмы? | АҖ төзекләндерү Кагыйдәләре | | | | |
| 8 | Биналар янында чүп савытлары тәүлегенә бер тапкырдан да ким чистартыламы? | АҖ төзекләндерү Кагыйдәләре | | | | |
| 9 | Биналарның фасадлары төзекләндерү кагыйдәләре белән билгеләнгән тәртиптә тотыламы? | АҖ төзекләндерү Кагыйдәләре | | | | |
| 10 | Биналарда, корылмаларда йорт билгеләре бармы? | АҖ төзекләндерү Кагыйдәләре | | | | |
| 11 | Ремонт, төзелеш һәм башка төр эшләр тәмамланганнан соң төзекләндерү эшләре | АҖ төзекләндерү Кагыйдәләре | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | яңартыламы? | | | | | |
| 12 | Биналарның (төзелмәләрнең, корылмаларның), биналарның милекчеләре тарафыннан үз вакытында чистарту буенча чаралар күреләме? | АЖ төзекләндерү Кагыйдәләре | | | | |
| 13 | Җир эшләрен башкаруга рөхсәт (ордер) алынганмы? | АЖ төзекләндерү Кагыйдәләре | | | | |
| 14 | Җир эшләрен башкарганда кирәкле таләпләр үтәләме, җир эшләре үткәрү урыннарында төзекләндерү эшләрен вакытында һәм сыйфатлы итеп торгызыламы? | АЖ төзекләндерү Кагыйдәләре | | | | |

«___» ______________ 20___ ел
(тикшерү кәгазен тутыру датасы күрсәтелә)

______________________________ _______________ __________________________

(тикшерү кәгазе тутырган зат вазыйфасы) (имза) (Тикшерү кәгазе тутырган зат фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда)